# КЕШЕ КАЙЧАН МАТУР БУЛА?

**Максат:** Укучыларда матурлыкка омтылу, гаделлек, тыйнаклылык, мәрхәмәтлелек, эчкерсезлек кебек югары сыйфатлар тәрбияләү. Татар әдәбиятының тәрбияви эчтәлегенең тирән булуын чагылдыру, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлар:** Шигырьләр, күрсәтмә материаллар, плакат, мәкальләр, иҗади биремле эшләр.

**Сыйнф сәгате барышы.**

**1.Оештыру моменты:**

Укучыларның кәефен, әзерлеген тикшереп алу.

**2. Сыйныф сәгатенең төп өлеше:**

Бүгенге сыйныф сәгатенә ни өчен шушы тема сайлап алынды? Укучыларның исемнәре нинди мәгънәгә ия, һәр исемнең матурлыгы, җисеменең дә матурлыгына тиң булырга тиешлеге хакында әңгәмә. Кеше гомер буе үзен тәрбияләргә тиеш икәнлегенә ышану.

**3. Йомгаклау:** Иң кирәкле сыйфатларны туплау, тормышта үз урыныңны табарга ярдәм итә.

**1.Укытучы**. *(Укый)*

Ү З Е М Ә /Мөхәммәт Мирза./

Сандугачлар сайравын да
Ишетә белү кирәк.
Чәчкәләрнең ачылуын
Иртәдән күрү кирәк.

Авылдашларны очратканда
Сәламли белү кирәк.
Сиңа төбәлгән күзләрнең
Серләрен белү кирәк.

Гаиләнең татулыгын
Саклый да белү кирәк.
Үзеңә тугры булганны
Хаклый да белү кирәк.

Киләчәкнең матурлыгын
Күзаллый белү кирәк.
Кайгыны да җиңеп була
Бәхеткә түзү кирәк.

Имәннәрне юкәләрдән
Аралый белү кирәк.
Зирәкләрне юләрләрдән
Аера белү кирәк.

Кемгәдер кирәклегеңне
һәрвакыт тою кирәк
Өлешеңә көмеш тигән
Нәфсеңне тыю кирәк.

Ваклыклардан, юклыклардан
Талчыкма әле йөрәк.

Гел кайгыдан тормый дөнья
Шатлана белү кирәк.

**Укытучы.** Шигырьнең эчтәлегенә тирәнрәк керү өчен,укучылар, мин сезгә карточкалар бирәм, сезнең шул сорауларга җавап әзерләвегез сорала:

1)Кеше өчен иң кирәк сыйфатларны санагыз!

2)“Матурлык күлмәк белән сәдәфтә түгел, оят белән әдәптә” мәкале белән килешәсезме? Аңлатып бирегез.

3)Матурлык, күркәм гадәтләр турында хикәя, әсәрләр беләсезме? Мөмкин күркәм гадәтләрне санарга.

4)“Үземә” шигырендә: ишетү-күрү, сәламләү- серләрен белү, саклау – хаклау, күзаллау – бәхеткә түзү, аралау –аеру, тою-тыю сүзләренең мәгънәсен аңлатыгыз.

*Укучыларның җавапларын тыңлау, фикер алышу. ( 1укучы кыскача эчтәлекне искә төшерә)*

**Укытучы.** Әмирхан Еникин “Матурлык”, “Әйтелмәгән васыять” әсәрләрендә кеше күңеленең күркәм сыйфатларын чагылдыра.

Гүзәллек дөньясына беренче адымнарыбызны атлаганда, матурлыкны күрә башлаганда, кешелекнең иң күркәм заты- бөек, мәрхәмәтле әниләребезне истән чыгармыйк. Бу дөньяда без яшибез икән, үзебездән соң килгән буынга аналарны олылау, туган җиребезне, туган телебезне, динебезне хөрмәт итү, табигатьне саклау кебек күркәм сыйфатларны, гореф – гадәтләрне, матур йолаларны яшь буынга тапшырырга, мирас итеп калдырыга тиешбез.

“Матурлык” хикәясен укыганнан соң, Ә.Еникиның иҗатын бәяләп, И.Юзеев аны “Күңел карурманнарының тургае” дип атаган.

**Укучы.** *(“Кеше кайчан матур була?” дигән шигырь сөйли.)*

Кеш кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт-
Иле өчен, халкы өчен
Яшәгәндә җан атып.
Замананың авырлыгын
Җилкәсенә алганда.
Олы данга ирешеп тә,
Кече булып калганда,
Олы җан булып калганга,
Олы җанлы булганга.

**Укытучы.** Әйе, матурлык - бик тирән мәгънәле сүз. Әйтем-сүзнең бизәге, мәкаль-сүзнең җиләге дигәндәй, тактага мәкальләр язылган. Шуларны укып, мәгънәсенә төшенергә тырышып карыйк әле. Сүз нәрсә турында бара?

1)Казан карасы китәр,
Намус карасы китмәс.

(*Экранда шигырь юллары ачыла, укучы укый*.)

Кеше өчен иң әүвәле - НАМУС, дигән.
Намусыңны сатып, итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен-көнен саткан кеше
Ике дөнья өчен дә ул явыз дигән.

2)Акылың булса, акылга ияр,
Акылың җитмәсә, мәкальгә ияр.

(*Экранда шигырь юллары ачыла, укучы укый*.)

Икенче иң кыйммәтлесе – АКЫЛ, дигән.
Акылсызда акыл ягы такыр, дигән.
Акылсызда намус та юк, иман да юк
Ялганга ант итеп барын саткан дигән.

3)Үгет-нәсихәт бездән,
Әдәп белү үзеңнән.
(*Экранда шигырь юллары ачыла, укучы укый.*)
Өченче иң кыйммәтлесе -ӘДӘП , дигән.
Әдәп – көчле мәхәббәткә сәбәп дигән.
Әдәпсездз бәхет тә юк, тәүфыйк та юк
Кеше исемен күтәрү дә, гаҗәп дигән.

4)Рәхимле бүре рәхимсез кешенең баласын асраган.

(*Экранда шигырь юллары ачыла, укучы укый.*)
Дүртенче иң кыйммәтлесе – КҮҢЕЛ, дигән.
Күңеле бозык кеше – кеше түге, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы, дигән
Яшәмә дә, үлеп җиргә күмел дигән.

5)Күркәм кием - тән зиннәте,
Күркәм холык – җан сихәте.

(*Экранда шигырь юллары ачыла, укучы укый.*)
Бишенче иң кыйммәтлесе – САБЫР, дигән.
Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән.
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр дигән.

Экранда укчылар җавабы буенча ромашка чәчәге таҗлары ачыла бара – намус, акыл, әдәп, күңел, сабыр, дип язылган сүзләр укыла.

*Ромашка таҗы ачылып бетә, уртадагы түгәрәктә “Кеше - җирнең гүзәл чәчәге”, - дип язылган.*

**Укытучы.** Ә хәзер ромашка таҗларын бер-бер артлы югалта барабыз, аның ямьсезләнүен күрәбез. Бу таҗларның берсе генә югалса да, кеше үзенең матурлыгын югалта икән. Димәк,тышкы матурлык кешенең акылын да, намуслылыгын да, күңел матурлыгын да әхлаклылыгын да билгеләми. Кеше өчен иң кирәге – эчке матурлык, кеше күңеленең матурлыгы. Матурлык безне кара уйлардан коткара, явызлыктан саклый. Безнең ерак әби – бабаларыбыз да һәрвакыт матурлыкка омтылганнар. Мөлаемлылык, ярдәмчеллек, эчкерсезлек, саф йөрәклелек –шундый күркәм сыйфатлар безгә алардан мирас булып калган. Кеше, нинди генә тормыш юлларын үтсә дә, үзе булып кала белгән, эчке матурлыгын саклаган шәхес булырга тиеш. Гүзәллек белән янәшә үзең дә шәфкатьлерәк, мәрхәмәтлерәк булырга тырышасың. Шуңа күрә, кечкенә яшьтән үк үз – үзеңә карата таләпчән булып, халкыбызның күркәм сыйфатларына ия булып, матурлыкка омтылып яшәргә тырышырга кирәк.

Шундый гүзәл, акыллы, әхлаклы кеше булып үсүегезне теләп, истәлеккә открыткалар тапшырам.

*Открыткага “Исеңдә тот! “шигыре язылган.*

Исеңдә тот!

Бәхет башы – намус, балам,
Намусыңнан аерылма син.
Талпынып очар чагыңда,
Канатың каерма син.
Җәлләмә һич хезмәтеңне,
Эшләгәннән кеше үлми.
Рәхмәт алып яшәмәсә,
Кеше үзе рәхәт күрми.
Булсын һәрчак кешеләргә
Ачык йөзең, шат күңелең.
Җанга уктай кадалмасын
Бәреп әйткән туры сүзең.
Кеше кешедән ким түгел,
Шуны, балам, һич онытма.
Йөрәгеңдә беркемгә дә
Гомер буе кинә тотма.
Кертеп куй син колагыңа,
Үзеңнән зур булып булмый.
Туган ил ул берәү генә
Өр яңадан туып булмый.
Яшәү бүләк иттем сиңа,
Буш ятмасын, яшәү ул – ут.
Ана сүзе иге була,
Мин әйткәнне исеңдә тот!